ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СРЕДНЕКИРМЕНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Ленина, д.16А, с. Средние Кирмени,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422171

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ УРТА КИРМӘН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Ленин ур., 16А нчы йорт, Урта Кирмән авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422171

тел.(факс): (85563) 2-92-38;2-92-44 e-mail: Skimer.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

**Карар** **Постановление**

№ 22 18 нче сентябрь 2019 ел

Референдум уздыру инициативасы турында

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 ел, 12 июнь, 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 ел, 6 октябрь, 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14, 22, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 20 статьясының 1 пункты, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Урта Кирмән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясы, Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге башкарма комитеты турындагы Нигезләмә нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге Башкарма комитеты К А Р А Р Б И Р Д Е:

1.Түбәндәге сораулар буенча җирле референдум үткәрү инициативасы белән чыгарга:

«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, 90 яшьтән өлкәнрәк гражданнар, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2020 елда 400 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

- Арташ авылы Карл Маркс урамы буенча юлга вак таш җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү);
- Арташ авылы урам утлары, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру(килешү буенча эш өчен түләү);

- Урта Кирмән авылындагы чишмәләр территорияләрен төзекләндерү (павильон урнаштыру, махсус техника ярдәмендә чишмә үзәнен тирәнәйтү, юлын вак таш белән җәю);
- Урта Кирмән авылында юлларны кардан чистарту.

« ӘЙЕ » « ЮК »

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен үз контролемә алам.

Мамадыш муниципаль районы
Урта Кирмән авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе Б.Ф.Хәсәнов